Зур Фролово төп гомуми белем бирү мәктәбе үзенең ишекләрен 1932 нче елда ачкан. Ул вакытта мәктәп 7 еллык кына булган. Бөек Ватан сугышы вакытында да мәктәп ишекләрен япмаган. Мәктәп үзенең тарихы белән горурлана. Мәктәп тарихы – ил тарихы ул.

Мәктәп Вера Фигнер акчасына салына. Ул танылган судья кызы, Тәтеш өязеннән. Авылыбыз кешеләре аның белән тыгыз элемтәдә була. Октябрь революциясеннән соң,  Вера Николаевна берничә тапкыр Тәтеш өязендәге авылларда була. Мәктәпкә, балалар йортларына булыша. Зур Фролово авылында ул укытучылар гаиләсе Иван Егорович Лаврентьев гаиләсендә туктала.  Аның хатыны Пелагея Андреевна да алдынгы карашлы укытучы була. Дуслары аны Поленька дип йөртәләр.

Иван Егорович укытучы булудан тыш, китапханә мөдире булып та эшләгән. Күп бала анасы булуына карамастан (гаиләдә 7 бала), Поленька курслар да алып бара, авыл советында да эшли.

1. Мәктәп төзелеше

Хатлар һәм башка архив материалларыннан күренгәнчә, Вера Фигнер үзенең якташларын кайгырткан. Пелагея Андреевна Лаврентьеваның Вера Фигнерга мәктәп төзелеше турында язылган хатлар моңа ачык мисал булып тора.

1929 нчы елның 15 нче апрелендә язылган хатны карыйк.

«…Сегодня коллективы начали ломать поповский дом и сегодня же перевезут его на площадь, а с завтрашнего начинают строить. Молодой избач (Сергей, старший сын Лаврентьевых) дело наладит живо, будет у нас своя читальня…».

1 нче октябрь,   1929 нчы ел.

«Ура! Милая Вера Николаевна! Ведь у нас во Фролове теперь есть по милости молодого избача изба-читальня, клуб, библиотека (все в одном большом здании). Сегодня в нем закончат класть голландки. Хотя залезли рублей на 70 в долг, но как-нибудь от спектаклей, где субботниками, актив заработает. Теперь ежедневно по очереди работают по 30—40 мужчин и женщин — копают под фундамент канавы в полтора метра глубины, грунт очень твердый, сколько переломали одних лопат, хорошо, что кузнецы оправляют их бесплатно.

19 нчы октябрь, 1929 нчы ел.

«…Дело у нас двигается. Стали возить песок и воду ежедневно по 10—12 лошадей и фундамент начали класть. Много требуется людей! Ну, вознаграждением будет красоваться школа, при которой квартира учителя и рабочая мастерская.. ».

2 декабрь,  1932 нче ел.

«...В воскресенье или 5-6-го будет открытие школы, вот уж тогда поикаете и Вы, милая Вера Николаевна! Ну уж, достанется Вам! Ведь это Вы заставили построить у нас такую школу, вложили в нее свои средства».

Шулай итеп, мәктәп үзенең ишекләрен ачкан. 1932 нче елда 20 яшькә кадәрге барлык егет һәм кызлар мәктәпкә белем алырга килгәннәр. Өлкән кешеләр арасында бу вакыйганы хәтерләүчеләр дә бар. Укый-яза белмәүче колхозчылар да читтә калмаган. Беренче директор Александр Егорович

Лаврентьевны кызы Аврора моны яхшы хәтерли. Өлкән сыйныфның яхшы укучылары авылның укый-яза белмәүчеләре белән сөйләшүләр алып баралар.

2. Мәктәп тормышы.

Мәктәп белем бирү йорты гына түгел, мәдәни чаралар үткәрелүче Ял үзегенә әверелә. Монда төп һәм өстәмә белем бирү дә керә. Мәктәптән тыш та күр чаралар үткәрелә. Ялны тематика буенча да уздыралар. Пионер организацияләрен, октябрятка кабул итүләрне шактый кеше хәтерли.

Спорт та мактаулы була. Бигрәк тә кече спортакидалар еш үткәрелә. Монда җиңүчеләр шәһәр һәм өлкә ярышларында катнаша.

Ял көннәрендә, теләсә нинди һава торышы булуына карамастан, пионерлар рюкзаклар асып походка чыкканнар, учаклар якканнар, пионер җырларын җырлаганнар.

Күп кенә балалар үзешчән сәнгатьтә дә катнашканнар. Мәктәп, ил тормышын чагылдырып төрле инсценировкалар куйганнар. Ул вакыттагы укучылар үзләренең мөстәкыйльлекләре белән дә аерылып торганнар.

3. Мәктәп директорлары.

1932 нче елдан 1961 нче елга кадәр Зур Фролово мәктәбе директоры булып Александр Егорович Лаврентьев. Аның хатыны Мария Александровна Лаврентьева балалар бакчасы оештырган. Өлкән кешеләр мәктәп янына күпләп җимеш агачлары утыртуын әле яхшы хәтерлиләр. Бераздан монда зур алма бакчасы барлыкка килгән.

Колхозга беренче трактор кайтуын да яхшы хәтерлиләр әле. Яшьләр яңа техниканы үзләштерә башлаган. Авылга белемле, укымышлы кешеләр кирәк булган. Белем алуга таләпләр дә арткан. Тыныч тормышта яшәүчеләр авылны тотрыклы иткәннәр. Туучылар саны да күбәйгән.

1941 нче елның 22 нче июне. Бу кара көннән соң мәктәпкә дә зур үзгәрешләр керә. Укытучылар составы кискен үзгәрә, ирләр (шул исәптән директор да) фронтка китә. Аларга алмашка хатын-кыз укытучылар килә.

Сугыш чорының авырлыгы яшүсмерләр, аналар һәм өлкәннәр өстенә төшә. Кырларда иген җыюда булышырга кирәк булганлыктан, укулар октябрь ахырыннан гына башлана торган була.

Мәктәпне 1943 нче елда тәмамлаучы Татьяна Васильевна Гарашина

болай дип искә ала: “Китаплар, дәфтәрләр һәм кара җитешми. Барысы да бик ярлы яшәделәр. Туйганчы ашарга да җитмәде. Мәктәпкә кемнең нәрсә бар, шуның белән йөрде. Җылы көн булса, яланаяк йөрделәр. Салкын көннәрдә – итектән. Сугышка авылдан 427 кеше китте. 228 кеше сугыш кырларында ятып калды.“

Зур Фролово авылында туган Шафранов Петр Григорьевич зур сугыш юлы уза. 112 нче укчы полкы сугышчысыннан генерал-полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 1945 нче елның 19 нчы апрелендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Аның исеме мәңгеләштерелгән. Зур Фролово һәм Буа шәһәрендә Шафранов исемен йөртүче урам бар. Мәктәбебез дә Советлар Союзы Герое Петр Григорьевич Шафранов исемен йөртә. Шафрановның батырлыгы турында без Тверь, Осташково, Ржев, Карачев, Велиж, Минск, Смоленск, Буа шәһәрләрендәге музейлардан таба алабыз.

Сугыш бетә. Ирләр дә туган якларына әйләнеп кайта. Мәктәп директоры

Александр Егорович Лаврентьев та мәктәп белән җитәкчелек итүне дәвам итә. Балаларга географиядән белем бирә. Аны “аяклы энцеклопедист” дип атыйлар. Мәктәп яңа тормыш белән яши башлый. Элеккеге чыгарылышлар мәктәп завучы Стебленко Анна Степановнны да җылы хисләр белән искә алалар. Ул 1946 нчы елга кадәр рус теле һәм әдәбиятыннан белем биргән.

Директорлар да шактый булган.

1961 нче елдан 1963 нче елга кадәр - Журавлев Николай Порфирьевич.

1963 нче елдан 1967нче елга кадәр - Мясников Петр Яковлевич.

1967 нче елдан 1973 нче елга кадәр - Никашин Герман Андреевич.

1973 нче елдан 1975 нче елга кадәр - Ионов Михаил Иванович.

1975 нче елдан 1982 нче елга кадәр - Хөсәенов Фатих Мостафинович.

1991 нче елдан 2012 нче елга кадәр - Руслова Надежда Павловна.

2012 нче елдан 2015 нче елга кадәр - Ханбиков Илгиз Фәридович.

2015 нче елдан 2017 нче елга кадәр– Садыйков Ленар Мөслихович.

2017 нче елдан 2018 нче елга кадәр – Мөхәмmәтҗанов Марат Илшатович

2018 нче елдан бүгенге көнгә кадәр – Кавиев Рамил Наилевич

Әйе, директорлар алышынган. Аларның һәркайсы нинди дә булса яңалык алып килергә тырышкан. Мәктәбебездә 3 ел директор булып торган, яраткан укытучыбыз Ханбиков Илгиз Фәридович бүген район мәгариф бүлеген җитәкли.

4. Укытучылар.

Мәктәптә Царьковлар, Хөсәеновлар, Лаврентьевлар, Никашиннар династиясе зур эз калдыра. Күп кенә чыгарылышлар үзләренең беренче укытучылары Есина Татьяна Васильевнаны (1943 нче елдан башлангыч сыйныфлар укытучысы), Масленцева Прасковья Петровнаны (1946 нчы елдан), Бастрикова Любовь Федоровнаны (1946 нчы елдан), Царькова Матрена Сергеевнаны (1946 нчы елдан), Панова Зоя Михайловнаны ( 1974 нче елдан) җылы хисләр белән искә алалар.

Фән укытучылары да еш алышынып торган . Күчелек укытучылар Буа шәһәреннән килеп эшләгәннәр. Гомерләрен балалар укытуга һәм тәрбияләүгә багышлаучылар да шактый булган. Орлова Наталья Матвеевна ( 1946 нчы елдан рус теле һәм әдәбияты укытучысы ), Орлов Корнелий Прохорович (1949 нчы елдан география укытучысы), Царьков Алексей Данилович (1949 нчы елдан физкультура укытучысы), Хөсәенова Тамара Анатольевна (1975 нче елдан география һәм биология укытучысы) , Полякова Нина Александровна (1979 нчы елдан рус теле һәм әдәбияты укытучысы), Масленцева Елена Анатольевна (1984 нче елдан башлангыч сыйныфлар укытучысы), Кудряшова Илсөяр Маһировна (мәктәпнең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары, 1985 нче елдан математика укытучысы).

Мәктәпнең бүгенге тормышы

Бүгенге көндә мәктәптә 11 укытучы укыта. Аларның 9 ы югары белемле, 2 се махсус-урта белемгә ия.

РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы грамотасы белән бүләкләнүче – 1

(Кудряшова Илсөяр Маһировна)

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесенә лаек булучылар -3 (Исмәгыйлева Гөлнара Таһировна һәм Садриева Кафия Камәртдиновна, Козлова Гөлинә Нурулловна).

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы – 1 (Козлова Гөлинә Нурулловна)

“Безнең яхшы укытучы” грантына ия булучылар - 2 (Исмәгыйлева Гөлнара Таһировна һәм Садриева Кафия Камәртдиновна).

Латыйпов Илдар Лензович - Татарстан Республикасының “Ел укытучысы 2014” бәйгесенең “Патриотлар үстерәбез” номинациясендә җиңүче.

Мясникова Татьяна Александровна - Татарстан Республикасының “Сыйныф җитәкчесе 2015” бәйгесендә җиңүче.

Мәктәп укучылары Халыкара, Бөтенроссия, республикакүләм, район бәйгеләрендә җиңеп чыгалар. Фән олимпиадаларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә уңышлы чыгыш ясыйлар.

“Каюм Насыйри укулары”, “Вахит Хаков укулары”, “Аксаков укулары” нда призлы урыннар алалар. Бөтенроссиякүләм яшь язучылар өчен “Илһам” бәйгесендә дә мактанырлыгыбыз бар. Спектакльләр белән дә бәйгеләрдә катнашабыз. Ел саен призлы урыннар алабыз.

2015 нче елның 30 нчы декабрендә фроловалылар өчен зур шатлык булды: ике катлы яңа мәктәп бинасы ачылды. Ул Советлар Союзы Герое Петр Григорьевич Шафранов исемен йөртә.